**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**Кырык өченче утырыш дүртенче чакырылыш**

**25 август 2025 ел №154 Олы Мәтәскә авылы**

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2015 елның 16 июнь 138 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче районы прокуратурасының 17.06.2025 ел, № 02-08-01-2024/Прдп 96-25-20920037 протестын карап, Теләче муниципаль районы авылҗирлеге Советы карарчыгарды:

1 Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы карарына 16.06.2015 ел № 138 «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» (22.03.2016 ел №21, 27.09.2018 ел №103, 19.11.2021ел № 37, 25.09.2023 № 99, 01.11.2024 № 130) түбәндәге үзгәрешләр:

Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципальрайонының Олы Мәтәскә авыл җирлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Регламентына:

А) 3.4 пунктта «бердәм порталда» сүзләреннән соң «яисә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының гражданны идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне тәэмин итә торган башка мәгълүмат системасында " сүзләрен өстәргә»;

Б) 7.10 бүлегенә 7.10.4.1 пункты өстәргә. Түбәндәге эчтәлекле: «7.10.4.1. Гражданнарның иминлеген тәэмин итү максатларында, аларның оператив-эзләү эшчәнлеген яисә Россия Федерациясенең иминлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, әлеге органнарның вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләрне Эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, иминлекне тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, Тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, дәүләт саклавы өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары белән электрон документ формасына һәм мөрәҗәгатьләргә җавапларны, хәбәрнамәләрне җибәрүгә.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Теләче муниципаль районы
Олы Мәтәскә авыл җирлегенең
башлыгы урынбасары Р.М.Салахиев.